


2023 елнын 18 октябрендə Мордовия Республикасы Матбугат vзəгендə Ватаныбызны яклаучыларга ярдəм фонды филиалынын 4 айлык эш нəтижəлəренə багышланган матбугат конференциясе уз-ды. Исегезгə тошерəбез, ул Россия Президенты Владимир Путин Указы нигезендə тозелде. Саранскида тобəк филиалы 2023 елнын 1 июнендə эшли башлады.
“Без демобилизациялəнгəн сугыш ветераннарына һəм һəлак булганнарнын гаилə əгъзаларына “бер тəрəзə” режимында барлык социаль ярдəм чараларын кvрсəтəбез. Шунысын да билгелəп vтəргə кирəк, фонд филиалы Саранск vзəгендə, Полежаев урамы, 113 йортта, транспорт белəн унайлы житеп була торган урында урнашкан. Бинада шулай ук халыкнын аз хəрəкəтлəнvче торкемнəре очен барлык шартлар да бар”, - дип билгелəп vтте “Ватанны яклаучылар” дəvлəт фонды филиалы директоры Алексей Герасименко.
Беренче июньнəн фонд филиалына 2700дəн артык кеше морəжəгать иткəн. Алар 3700дəн артык торле ярдəм сораган. Хəл ителгəн мəсьəлəлəр саны 90% тəшкил итə. Башлыча демобилизациялəнгəн сугыш хəрəкəтлəре ветераннары, һəлак булганнарнын гаилə əгъзалары һəм гамəлдəге хəрбилəр морəжəгать итə. Ин кин таралган сораулар - сугыш хəрəкəтлəрендə катнашучы, һəлак булган кешенен гаилə əгъзасы танык-лыкларын алу, юридик һəм медицина ярдəме кvрсəтv һəм башкалар.
Фонд филиалында 25 социаль координатор эшли. Алар барысы да Тvбəн Новгород идарə институтында - РАНХИГС филиалында укыган. Республиканын һəр районында vз социаль координаторы бар. Моннан тыш, тобəкнен 17дəн артык министрлыгы һəм ведомствосы белəн килешvлəр тозелгəн. Алар арасында Россиянен социаль фонды, социаль яклау министрлыгы, Мəгариф министрлыгы, Сəламəтлек саклау министрлыгы, Мəдəният министрлыгы, МФЦ, мəшгульлек Үзəге һəм башкалар.
«Наш филиал показал стабильную работу и востребованность, поэтому центральный аппарат Госфонда «Защитники Отечества» принял решение об увеличении кадрового состава нашего отделения. Простая статистика говорит о том, что в целом по стране у нас в 2,1 раза больше количества обращений и в 2,6 раза больше положительно решаемых вопросов. Хочу поблагодарить Главу Мордовии Артёма Алексеевича Здунова и Правительство республики за особое внимание, которое было уделено формированию филиала фонда. Благодаря этому наше региональное отделение не только соответствует всем предъявленным требованиям, но и по оснащению является одним из лучших в стране. Здесь есть все условия, чтобы оказывать комплексную помощь ветеранам СВО в адаптации к мирной жизни», - ди Алексей Герасименко.
Башкарылган ярдəмнəрнен берничəсе - ветераннарны демобилизациядəн сон эшкə урнашырга, Крымда реабилитация vтəргə, вафат булган батырнын балаларына Артекта ял итəргə, психологик ярдəм һəм башка, һəм башка ярдəмнəр кvрсəтəлəр бу форнд хезмəткəрлəре бергəлəп. Шундый ярдəм дə була. Атюрьево районында ветеранга протезын дорес йортергə булышалар. Тагы бер мисал. “Ватанны яклаучылар” фондынын тобəк филиалы хезмəткəрлəре, махсус операция ветераны Александрга «двойнигы» белəн (исеме, фамилиясе, əтиенен исеме, туган коне тулысынча бертосле) бурыч

проблемасын хәл итәргә булышканнар. 2020 елда ук «Госуслуги» га ир-атка Кемерово олкәсеннән тvләнмәгән штрафлар килә башлый. Суд Александрнын банк счетларын кулга ала, һәм ул банк карточкасыннан файдалана алмый. Ир-атка судта vз хокукларын яклау һәм булмаган бурычларын бетерv очен адвокатларга акча сарыф итәргә туры килә. Аннары махсус хәрби операция башлана, анда Александр ярты ел дәвамында катнаша. Ойгә кайткач, хәл vзгәрми: бурычлар килvен дәвам итә. Оч ел эчендә аларнын гомуми суммасы 100 мен сумга якын була.
Ветеран Мордовиядәге “Ватанны яклаучылар” фонды филиалына ярдәм сорап морәҗәгать итә. Юристлар документларны ойрәнәләр һәм Россия Федерациясенен Цифрлы vсеш, элемтә һәм массакvләм коммуникацияләр министрлыгына җибәрелгән гаризаны тозергә ярдәм итәләр. Ведомство гаризаны оператив рәвештә карый һәм мәгълvмат базасына тозәтмәләр кертә. Нәтиҗәдә, ветераннан барлык бурычлар алына.
Фонднын адресы: Саранск шәһәре, Полежаев урамы, 113. Телефон: 8 (8342) 39-28-82.

**Наилә НАСЫРОВА**